- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 статьясы 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза - дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос. Гариза стандарт бланкта тутырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Суд тәртибендә эшкә яраксыз яисә чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек булдыру һәм опекун яки попечитель билгеләү | 48-ФЗ номерлы Федераль закон; 927 номерлы РФ карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Аңа карата опека яисә попечительлек билгеләүгә мохтаҗ затның йә опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча Башкарма комитет | 7-ТРЗ, 8-ТРЗ номерлы ТР законнары; 48-ФЗ номерлы Федераль законның11 ст.; 927 номерлы РФ карарының 4, $4^1$ п. |
| О | опека (попечительлек) булдыру һәм опекун (попечитель) билгеләү турында, йә опекун яисә попечительне билгеләүдән баш тарту турында карар | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша, электрон адреска) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә җибәрелә | 927 номерлы РФ карары; 8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карарының 1 пункты таләпләре нигезендә опекун тарафыннан документ рәвешендә яисә электрон документ формасында бирелгән гариза;<br>2. эш урыныннан соңгы 12 айда хезмәт хакы күләме һәм вазыйфасы күрсәтелгән белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә булмаган гражданнар өчен - керемнәрне раслаучы башка документ (пенсионерлар өчен - пенсия таныклыгының күчермәләре;<br>3. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә бирелгән, опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданны таныклау нәтиҗәләре буенча сәламәтлек торышы турында медицина бәяләмәсе;<br>4. балигъ булган опекага алына торган затның опекун белән яшәвенә опекун булырга теләк белдергән граждан белән яшәүче, 10 яшькә җиткән балаларның фикерләрен исәпкә алып, балигъ булган гаилә әгъзаларының язмача ризалыгы (опекун гаиләсе белән балигъ булган опекага алынган затның бергә яшәве турында опекун карар кабул иткән очракта); | РФ ГК; 48-ФЗ номерлы Федераль закон; 927 номерлы РФ карары; 8-ТРЗ номерлы ТР законы |

| | | |
|---|---|---|
| | 5. кагыйдәләрдә (булган очракта) опекун булырга теләк белдергән гражданның әзерлек узу турында документы;.<br>6. автобиография.<br>Ата-аналар, әбиләр, бабайлар, апа-сенелләр, балигъ булган тәрбияләнүчеләрнең опекуны яки попечителье булырга теләк белдергән ата-аналар, әбиләр, бабайлар, апа-сенелләр һәм оныклар, алар белән күрсәтелгән гражданнар опекун итеп билгеләү турында гариза биргән көнгә кимендә 10 ел бергә яшәгән булсалар (алга таба - опекун булырга теләк белдергән якын туганнар) опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>1. «Дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм башка документларны электрон документлар рәвешендә рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе турында"Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 7 июлендәге 553 номерлы карарының 1 пункты таләпләре нигезендә опекун тарафыннан документ рәвешендә яисә электрон документ формасында бирелгән гариза;<br>2. балигъ булганнарга туганлыкны раслый торган документлар;<br>медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча опекун булырга теләк белдергән гражданның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләнгән тәртиптә бирелгән сәламәтлеге торышы турында медицина бәяләмәсе | |
| 2.6. Дәүләт органнары, жирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>1. Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнары яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнар тарафыннан пенсия алуны раслаучы белешмә - опекун булырга теләк белдергән пенсионер гражданга карата;<br>2. яшәү урыныннан йорт (фатир) кенәгәсеннән өземтә яисә торак урыныннан файдалану хокукын яисә торак урынына милек хокукын раслаучы башка документ һәм яшәү урыныннан финанс шәхси счет күчермәсе;<br>3. опекун булырга теләк белдергән гражданның Эчке эшләр органнары тарафыннан бирелгән гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә анлы рәвештә жинаять кылган өчен хөкем ителгәнлеге турында белешмә;<br>4. торак биналарның тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан бирелгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында белешмә (опека һәм попечительлек органы запросы буенча бирелә);<br>5. гражданны закон көченә кергән эшкә яраксыз (чикләнгән эшкә сәләтсез) дип тану турында суд органы карары;<br>6. опекун булырга теләк белдергән якын туганының балигъ булган опекадагы затка карата 18 яше тулганчы тиешенчә мөрәҗәгать итмәве турында фактлар булмау хакында опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсе.<br>7. ведомствоара запрос опека һәм попечительлек органында күрсәтелгән мәгълүматлар булган очракта җибәрелми.<br>8. ведомствоара запрос опекун булырга теләк белдергән граждан гариза һәм кирәкле барлык документларны биргән көннән 2 эш көне эчендә җибәрелә | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, жирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | 1. Күрсәтелгән документларның әлеге Регламентның 2.5 п. күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>2. Тапшырыла торган документларда төзәтмәләр булу.<br>3. Мөрәҗәгать опека яисә попечительлек билгеләүгә мохтаж затның йә опекун яисә попечитель булырга теләк белдергән затның яшәү урыны буенча түгел. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган. | 48-ФЗ номерлы Федераль закон; 927 |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | | номерлы РФ карары |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | 601 номерлы Президент Указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.<br>Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән сорау ял (бәйрәм) көненнән соң эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бинала булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнен сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http//uslugi.tatar.ru/ сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮнең еракта урнашкан эш урыннарында күрсәтелми. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә | 63-ФЗ номерлы, 210-ФЗ номерлы Федераль |

| | | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин | законнар; РФ Хөкүмәтенең 553 номерлы карары |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) башкару үзенчәлекләре**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә эзлекле гамәлләр тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү;
- гаризалар һәм документлар кабул итү, аларны теркәү;
- дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү;
- опекун булырга теләгән затның яшәү шартларын тикшерү;
- опекунны (попечительне) билгеләү турында карар кабул итү яки опекунны (попечительне) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү;
- дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;
- техник хаталарны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче опека һәм попечительлек органына (алга таба - бүлек) шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән, дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча да, консультацияләр бирә.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү предметы буенча консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, бирелә торган документлар формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризалар һәм документлар кабул итү, аларны теркәү.

3.3.1 Гариза һәм документларны кабул итү буенча административ процедураны башкару өчен гариза бирүче шәхсән, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, йә заказлы почта аша гариза һәм документлар бирү нигез булып тора.

Кабул итүне алып баручы бүлек белгече башкара:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү;

документлар булу-булмавын тикшерү;

бирелгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда төзәтүләр, сызылган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтмәләр булмау).

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, бүлек белгече гариза бирү ысулына карап, гаризаны, кабул итү датасы турында тамга белән, һәм аңа теркәп бирелә торган документларны заказлы почта аша яки электрон почта белән җибәрә.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кире кайтара.

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, бүлек белгече кергән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша запрослар җибәрә:

мөрәҗәгать итүче белән берлектә теркәлгән гражданнар турында белешмәләр бирү турында яисә торак урынынан файдалану хокукын яисә торак урынга милек хокукын раслаучы документ, опекун булырга теләк белдергән гражданның яшәү урынынан финанс шәхси счеты күчермәсен бирү турында (вәкаләтле органнарга);

опекун булырга теләк белдергән гражданның гражданнарның сәламәтлегенә каршы уйланылган җинаять өчен хөкемгә тартылуы турында белешмә бирү турында (эчке эшләр органнарына);

торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында белешмә бирү хакында (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә);

пенсионер булган опекун булырга теләк белдергән гражданга карата пенсия алуны раслый торган белешмә бирү турында (Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнарына яисә пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнарга);

опекун булырга теләк белдергән якын туганының опекага алынган зат белән 18 яше тулганчы тиешенчә үз-үзен тотмавы турында (опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсе бирү хакында (элеккеге яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органнарына).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турында запрос.

3.4.2 Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре, ведомствоара электрон бәйләнешлар системасы аша кергән запрослар нигезендә, законнар белән билгеләнгән срокта соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә документларны (белешмәләрне) бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.5. Опекун булырга теләгән затның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.1. Опекун булырга теләк белдергән гражданинны (опекун булырга теләк белдергән якын туганнарыннан тыш) опекун итеп билгеләү максатыннан, бүлек белгече аның яшәү шартларын тикшерә, аның барышында аның опекун (попечитель) булуына комачаулаучы шартлар булмау билгеләнә.

Опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшергәндә, опека һәм попечительлек органы белгече торак-көнкүреш шартларын, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның опекун вазифаларын үтәүгә сәләтен, шулай ук аның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне бәяли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура опекун яки попечитель булырга теләгән затның гаризасын теркәгәннән, соң җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.2 Тикшерү нәтиҗәләре опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү турындагы актта күрсәтелә (4 нче кушымта) (алга таба - гражданның яшәү шартларын тикшерү турында акт).

Тикшерү турындагы акт 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданга җибәрелә, икенчесе бүлектә саклана.

Тикшерү турындагы актка опекун булырга теләк белдергән граждан тарафыннан суд тәртибендә дәгъва белдерелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү уздырылган көннән алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун булырга теләк белдергән гражданның яшәү шартларын тикшерү.

3.5.3 Опекун булырга теләк белдергән якын туганын опекун итеп билгеләү максатыннан, бүлек белгече яшәү шартларын тикшерә, аның барышында Россия Федерациясе Граждан кодексы тарафыннан опекун (попечитель) итеп билгеләнүгә комачаулык итүче шартлар булмау билгеләнә.

Опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшергәндә, опека һәм попечительлек органы белгече торак-көнкүреш шартларын, мөрәҗәгать итүченең шәхси сыйфатларын һәм мотивларын, аның опекун вазифаларын үтәүгә сәләтен, шулай ук аның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне бәяли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура опекун яки попечитель булырга теләгән затның гаризасын теркәгәннән соң, җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун булырга теләк белдергән якын туганының яшәү шартларын тикшерү.

3.5.4. Тикшерү нәтиҗәләре опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданинның яшәү шартларын тикшерү турындагы актта күрсәтелә (4 нче кушымта) (алга таба - гражданның яшәү шартларын тикшерү турында акт).

Тикшерү турындагы акт 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданга җибәрелә, икенчесе бүлектә саклана.

Тикшерү турындагы актка опекун булырга теләк белдергән граждан тарафыннан суд тәртибендә дәгъва белдерелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура тикшерү уздырылган көннән алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекун булырга теләгән якын туганының яшәү шартларын тикшерү турында акт.

3.6. Опекунны (попечительне) билгеләү турында карар кабул итү яки опекунны (попечительне) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.6.1 Бүлек белгече опека һәм попечительлек комиссиясенә (алга таба - комиссия) бирү өчен документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган һәм комиссиягә карауга җибәрелгән документлар пакеты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Утырышта комиссия опекун (попечитель) билгеләү яки опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Опекун (попечитель) итеп балигъ булган эшкә сәләтле граждан гына билгеләнә ала. Шул ук вакытта аның әхлакый һәм башка шәхси сыйфатлары, опекун яки попечитель бурычларын үтәү сәләте, мөрәҗәгать итүче белән опекага яки попечительлеккә мохтаҗ булган зат арасында булган мөнәсәбәтләр, мөмкин булса - опекага алынган кешенең теләге исәпкә алынырга тиеш.

Опека һәм попечительлек буенча комиссия утырышын үткәрү барышы, шулай ук аның бәяләмәсе утырыш беркетмәсендә теркәлә. Күрсәтелгән беркетмәләр комиссия утырышлары беркетмәләрен теркәү журналында теркәлә (7 кушымта).

Комиссия әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче биргән документлар, әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктлары нигезендә алынган белешмәләр (документлар) һәм гражданның яшәү шартларын тикшерү турында акт (якын туганының яшәү шартларын тикшерү турында акт) нигезендә опекун (попечитель) билгеләү турында карар яисә опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Түбәндәге нигезләрнең берсе булса да, комиссия тарафыннан опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителә:

- гариза бирүче биргән документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүматлар ачыклану;

- мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 1.2 пункты таләпләренә туры килмәве (мөрәҗәгать итүчене суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип тану, мөрәҗәгать итүченең ата-ана хокукыннан мәхрүм ителүе, мөрәҗәгать итүченең опека һәм попечительлек билгеләнгән вакытта гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә карата алдлы җинаять кылган өчен хөкем ителгән булуы);

- билгеле бер гражданны опекун яки попечитель итеп билгеләү опекунга алынучы мәнфәгатьләренә туры килми (опекун бурычларын тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән; опекун бурычларын үтәүгә комачаулаучы авыру белән интегә; даими яшәү урыны булмаган, санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга җавап бирми торган торак урыннарда яши торган хәлләрне ачыклау);

- гражданинның (якын туганының) яшәү шартларын тикшерү актында Россия Федерациясе Граждан кодексы белән билгеләнгән опекун итеп билгеләнүгә комачаулык итүче шартларның булуы чагылдырылган.

Комиссия утырышы нәтиҗәсе булып беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана торган карар кабул итү тора.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.4. Опекун советы бәяләмәсе һәм документларның тулы пакеты нигезендә белгеч Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү турында карар проектын (1 нче кушымта) яки эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән граждан өстеннән опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә имзага җибәрә. Карар ике нөсхәдә төзелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: җитәкчегә кул куюга юнәлдерелгән карар проекты.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.5. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе опекуннар советы бәяләмәсен карый һәм опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү турында карарга (алга таба - билгеләү турында карар) яки эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән граждан өстеннән опекун (попечитель) билгеләүдән баш тарту турында карарга (алга таба - баш тарту турындагы карар) кул куя.

Процедураның нәтиҗәсе: 2 нөсхәдә имзаланган карар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.6. Бүлек белгече теркәү журналында билгеләнү турында карарны терки, билгеләнгән үрнәктәге таныклыкны (3 нче кушымта) рәсмиләштерә.

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6.7. «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында билгеләнгән очракларда, опека һәм попечительлек органы үз вазыйфаларын үтәүче опекунны билгеләү турында карар кабул итә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы карары белән расланган эшкә сәләтсез балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә опека һәм попечительлек гамәлгә ашыру турында килешү төзи.

3.7 Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.7.1. Билгеләү турында карарның бер нөсхәсе һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклык яки баш тарту турында карар мөрәҗәгать итүчегә ул килгән көнне бирелә.

Опека һәм попечительлек органы баш тарту турында карар белән бергә мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган барлык документларны кире кайтара һәм шикаять бирү тәртибен аңлата. Күрсәтелгән документларның күчермәләре опека һәм попечительлек органында саклана.

Процедураның нәтиҗәсе: билгеләү турында бирелгән карар һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклык яки баш тарту турында карар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла.

3.8 Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче бүлеккә тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза ( 8 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия булган, техник хатаның булуын таныклаучы документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшырыла.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, теркәп бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң, бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге Регламентның 3.6.4-3.6.6 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән), техник хата булган документ оригиналын алу белән, шәхсән үзенә бирә яки мөрәҗәгать итүче адресына почта аша (электрон почта аша) документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Югары вазыйфаи затлар (дәүләт хакимияте органнары) тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп торуны турыдан-туры гамәлгә ашыралар:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры (алга таба – министр), 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6; телефон (843) 231-79-98, факс (843) 238-41-44;

сәламәтлек саклау министры урынбасары, 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6; телефон (843) 231-79-38;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы эшләр идарәсенең гражданнар хатлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү секторының әйдәүче консультанты, 420111, Казан ш., Островский ур., 11/6; телефон (843) 231-79-84.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту дәүләт вәкаләтләрен үтәү турында кирәкле документлар, хисаплар һәм мәгълүмат соратып алуны, тикшерүләр үткәрүне, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, карарлар карау һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять биргән мөрәҗәгать итүчеләргә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш башкаруны алып бару тикшерүләр билгеләнгән тәртиптә үткәрелә;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшерү уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда, дәүләт хезмәте күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә, гамәлләрнең үтәлешен контрольдә тоту максатыннан, Башкарма комитет Җитәкчесенә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контроль Башкарма комитет Җитәкчесенең дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы урынбасары, шулай ук опека белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы житәкчесе мөрәҗәгать итүчеләр мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карамаган өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе житәкчесе (житәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкка ия.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка ия.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең ачыклыгы ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче Башкарма комитет хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына), Башкарма комитетка, Башкарма комитет Җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) муниципаль берәмлек советына судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү хокукына ия.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү срокларын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган документлар яисә мәгълүмат, гамәл кылу таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын һәм тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенен башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче тапкыр кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә булмаган һәм (яисә) хаталы булуы күрсәтелмәгән документларны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясы 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә югары органга кергән шикаять (булганда) аны теркәгәннән соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга шикаять биргән очракта, мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән баш тарткан очракта, яисә җибәрелгән хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта, яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылган очракта - аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаять үз эченә алырга тиеш:

1) аларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең исеме,

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда), яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән, кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган алынган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару рәвешендә дә, канәгатьләндерелә;

шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Кушымта (белешмә өчен)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Житәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 985 номерлы карарына 3 кушымта

**Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар (опекун яки попечитель).

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнар җыелмасы, 26.01.2009, № 4, 445 ст., 04.08.2014, № 31, 4398 ст.);
- 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);
- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 3185-I номерлы РФ Законы) («Халык депутатлары Советы һәм Россия Федерациясе Югары Советы ведомостьлары», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.);
- «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122 - ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - дәүләт теркәве турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, 3594 ст.);
- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31 (1к), 3451 ст.);
- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);
- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, № 43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең жирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);
- Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2011 елның 29 июлендәге 1046 номерлы боерыгы «Җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләр буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентларын раслау турында»;
- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);
- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);
- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);
- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- гомерлек тәрбияләп карап тоту шартнамәсе — гражданин үзенә караган күчемсез милекне рента түләүче милкенә тапшыра, ә тегесе, үз чиратында, гражданны һәм (яки) күрсәтелгән өченче затны гомерлеккә тәрбияләп карап тотарга йөкләмә ала торган килешү;
- «рента бирүче» - рента түләүче;
- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);
- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;
- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзү өчен рөхсәт | РФ ГК; № 48-ФЗ ; № 8-ЗРТ |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | Устав, № 7-ЗРТ |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү боерык формасында яисә опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирүдән баш тарту хат формасында. | ГК; № 48-ФЗ; № 8-ЗРТ |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган | 1. опекун яки попечительнең опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзү өчен рөхсәт итү турында гаризасы (сәбәпләрен күрсәтергә);<br>2. опека яки попечительлек булдыру һәм опекун яки попечительне билгеләү турында хокукый акт күчермәсе яки | РФ Конституциясе; РФ ГК; № 48-ФЗ; № 8-ЗРТ |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | опекун таныклыгы;<br>3. гражданны эшкә яраксыз яки чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>4. опекага алынучының гаилә составы турында оештыру-хокукый рәвешкә бәйсез рәвештә торак-коммуналь хуҗалык оешмасыннан белешмә, бирелгән көннән алты ай гамәлдә;<br>5. опекага алынган затның торакка хокукын билгеләүче документ күчермәсе;<br>6. опекага алынучынын торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты;<br>7. гражданның аның белән гомерлек рента шартнамәсе төзү турында гаризасы (гомерлеккә тәрбияләп карап тору) һәм рента шартнамәсен төзүгә ризалык турында гаилә әгъзалары гаризасы;<br>8. рента түләүченең паспорт күчермәсе (алга таба - «ре нта бирүче»);<br>9. рента түләүченең гаилә составы турында оештыру-хокукый рәвешкә бәйсез рәвештә торак-коммуналь хуҗалык оешмасыннан белешмә;<br>10. «рента бирүченең» керемнәре турында һәм «рента бирүченең» гаилә әгъзаларының җыелма кереме турында белешмә;<br>11. «рента бирүченең» эш урыныннан белешмә һәм характеристика, шулай ук «рента бирүченең» барлык гаилә әгъзаларының эш урыннарыннан белешмә;<br>12. рента түләүченең милеге турында мәгълүмат.<br>* Опекага алынган кеше мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе түбәндәге очракта туктатылырга мөмкин: опекун яки попечительнең, рентодательнең үз бурычларын үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве; опекадагы затны стационар социаль хезмәт күрсәтүгә җибәрү яки үлеме | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган опекага алынган затнын (эшкә яраксыз затның) милке турында мәгълүмат | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелмәгән;<br>опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу. | РФ Конституциясе;<br>РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8-ЗРТ |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълумати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълумати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Д әүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекуннарга һәм попечительләргә опекага алынган затның гражданлык һәм милек хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү һәм консультация бирү; опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзү мәсьәләсе буенча мәгълүмат бирү һәм консультация бирү;

- гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

- бирелгән документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигезләр билгеләү өчен, әлеге административ регламентта каралган таләпләргә туры килүгә тикшерү үткәрү;

- Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында запрос;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.2. Конс ультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- мөрәҗәгать итүчеләрне һәм хокуклы вәкилләрне опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән таныштыра;

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсен төзүгә рөхсәт бирү өчен, кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплы.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5. пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- опекун (попечитель) һәм рента түләүче булырга теләүче граждан тарафыннан бирелгән кирәкле документларның булуын тикшерә; кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

Әлеге регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге регламентның 3.3.1. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында җибәрелгән запрос.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек бүлеге органнары соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек аша формалаштыру яисә, соратып алына торган белешмәләр булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары запрослары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: запроска җавап яки әлеге регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт итү турында боерык проектын әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт бирү турында боерык, 3.8. пункты нигезендә әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.5.1. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклау вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, жирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтижәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтижәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Житәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә жаваплылыкка тарту өчен жибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге житәкчесе һәм Башкарма комитет Житәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең жаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Житәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен жаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәжәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәжәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәжәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәжәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәжәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәжәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтижәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтижәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган житәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган житәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша жибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәжәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәжәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәжәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм жавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән к аралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә сонга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән анлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**

**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 21 номерлы карарына 4 кушымта

**Балигъ булган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан балигъ булган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнар җыелмасы, 26.01.2009, № 4, 445 ст.);
- 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 04.08.2014, № 31, 4398 ст.);
- Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексы (алга таба - РФ ТК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст.);
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31-нче номерлы 4179 ст.);
- «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - дәүләт теркәве турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, 3594 ст.);
- «Россия Федерациясендә торак фондын хосусыйлаштыру турында» 1991 елның 4 июлендәге 1541 - I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 1541-1 номерлы Закон) («Халык депутатлары съезды һәм РСФСР Югары Советы ведомостьлары» 11.07.1992, № 28, 959 ст.);
- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 3185-1 номерлы РФ Законы) («Халык депутатлары Советы һәм Россия Федерациясе Югары Советы ведомостьлары», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.);
- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31 (1к), 3451 ст.);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, №17, 1755 ст.);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, № 43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

- - Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- - Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Эшкә яраксыз балигъ булган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү | РФ ГК; № 48-ФЗ ; № 8-ЗРТ |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | Устав,<br>№ 7-ЗРТ |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү турында боерык, яки опекага алынган зат катнашыннан башка торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү турында боерык, яки торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирүдән баш тарту | ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8-ЗРТ |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. опекага алынган зат мәнфәгатьләрен искә алып, торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт алу турында опекун гаризасы;<br>2. әлеге учреждениедә булган эшкә яраксыз затка карата опекун вазыйфаларын башкаручы сәламәтлек саклау дәвалау учреждениесе администрациясенең (яисә социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең) опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт алу турында гаризасы;<br>3. опека булдыру һәм опекун билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык, карар һ.б.);<br>4. гражданны эшкә яраксыз дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>5. опекага алынган затның паспорт күчермәсе | РФ Конституциясе; РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8-ЗРТ |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | - Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) алынган опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында мәгълүмат | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелмәгән;<br>опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу. | РФ Конституциясе;<br>РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8-ЗРТ |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Д әүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча опекуннарга мәгълүмат бирү һәм консультация бирү; әгәр опекага алынган зат тарафыннан торакны хосусыйлаштыру хокукы элек кулланылган булса, опекага алынган зат катнашыннан башка торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча опекуннарга мәгълүмат бирү һәм консультация бирү;

- гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

- бирелгән документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигезләр билгеләү өчен, әлеге Административ регламентта каралган таләпләргә туры килүгә тикшерү үткәрү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.2. Конс ультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән опекага алынган затның хокуклы вәкилен таныштыра;

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыру өчен рөхсәт бирү өчен кирәкле документларның булуын тикшерә; кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- докуменлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

Әлеге регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге регламентның 3.3.1. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында җибәрелгән запрос.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек бүлеге органнары соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- запросны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган белешмәләр булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары запрослары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: запроска җавап яки әлеге регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыру өчен рөхсәт бирү турындагы боерык проектын әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә торакны хосусыйлаштыру өчен рөхсәт бирү турындагы боерык, 3.8. пункты нигезендә әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.5.1. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты Татарстан опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклау вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**

**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 95 номерлы карарына 5 кушымта

**Опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнар җыелмасы, 26.01.2009, № 4, 445 ст.);
- 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);
- Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексы (алга таба - РФ ТК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст.);
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасынын 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);
- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 3185-I номерлы РФ Законы) («Халык депутатлары Советы һәм Россия Федерациясе Югары Советы ведомостьлары», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.);
- «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122 - ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - дәүләт теркәве турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, 3594 ст.);
- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31 (1к), 3451 ст.);
- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, №17, 1755 ст.);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, №43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

- 1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – м униципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә опекунга рөхсәт бирү | РФ ГК; № 48-ФЗ; № 8-ТРЗ |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | Устав, № 7- ТРЗ |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү | Балигъ булган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә торакны | РФ ГК; |

| | | |
|---|---|---|
| нәтиҗәсен тасвирлау | хосусыйлаштыруга опекунга рөхсәт бирү турында боерык, яки опекага алынган зат катнашыннан башка торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү турында боерык, яки торакны хосусыйлаштыруга рөхсәт бирүдән баш тарту | № 48-ФЗ;<br>№ 8- ТРЗ |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1.опекага алынган затныкы булган торакны наемга (опекага алынган затның милкенә хокук алудан тыш) бирүгә рөхсәт алу турында опекунның (хокуклы вәкиленең) гаризасы;<br>2. әлеге учреждениедә озак вакыт дәваланучы эшкә сәләтсез затка карата опекун вазыйфаларын башкаручы учреждение администрациясенең опекагадагы затның торагын наемга алуга (опекага алынган затның милкенә хокук алмыйча) рөхсәт турында гаризасы;<br>3. әгәр дә торак гомуми өлешле милектә булса, опекага алынган затныкы булган торакны (бүлмәне) наемга бирүгә рөхсәт бирү турында милектәш (булган очракта) гаризасы;<br>4. опека булдыру һәм опекун билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык);<br>5. гражданны эшкә яраксыз (чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз) дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>6. опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) паспорт күчермәсе;<br>7. фатирларны (йортларны) гражданнар милкенә тапшыру турында шартнамә күчермәсе;<br>8. опекадагы затның мөстәкыйль яшәү мөмкинлеге булмавы турында медицина бәяләмәсе;<br>10. опекага алынган затның торагын наемга бирү турында шартнамә проекты күчермәсе | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8- ТРЗ |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) мәгълүмат | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен | Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән | РФ ГК; № 48-ФЗ;<br>№ 8- ТРЗ |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелмәгән;<br>опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алынган затныкы булган торакны наемга (опекага алынган затның милкенә хокук алудан тыш) бирүгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча опекунга мәгълүмат һәм консультация бирү;

- гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

- бирелгән документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигезләр билгеләү өчен, әлеге Административ регламентта каралган таләпләргә туры килүгә тикшерү үткәрү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы әлеге Административ регламентның кушымтасында күрсәтелгән.

3.2. Консультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән опекага алынган затның хокуклы вәкилен таныштыра;

- опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документларның булуын тикшерә; кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларнын нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

Әлеге регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.4. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында җибәрелгән запрос.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек бүлеге органнары соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган белешмәләр булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары соратулары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә - опекага алынган затныкы булган торакны наемга бирүгә рөхсәт бирү турындагы боерык проектын әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекага алынган затныкы булган торакны наймга бирүгә рөхсәт бирү турындагы боерык, 3.8. пункты нигезендә әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.6.1. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.8.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече боерык бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклау вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.8.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән унайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**

**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 985 номерлы карарына 6 кушымта

**Опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнар җыелмасы, 26.01.2009, № 4, 445 ст.);

- 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

- Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексы (алга таба - РФ ТК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), 14 ст.);

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);

- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 3185-I номерлы РФ Законы) («Халык депутатлары Советы һәм Россия Федерациясе Югары Советы ведомостьлары», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.);

- «Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәве турында» 1997 елның 21 июлендәге 122 - ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - дәүләт теркәве турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, 3594 ст.);

- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31 (1к), 3451 ст.);

- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, № 43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

- Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2011 елның 29 июлендәге 1046 номерлы боерыгы «Җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә тапшырылган вәкаләтләр буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең типлаштырылган административ регламентларын раслау турында» (алга таба - ТРССМ 1046 номерлы боерыгы);

- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү | РФ ГК; № 48-ФЗ; № 8-ТРЗ |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | Устав,<br>№ 7- ТРЗ |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү турында боерык яки опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирүдән баш тарту | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8- ТРЗ |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. опекага алынган затның милке (мәҗбүри шарт - опекага алынган затның мөлкәт хокукларын саклау һәм опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә алыш-биреш үткәрү) белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү турында опекун яки попечитель (хокуклы вәкил) гаризасы. Опекага алынган затның милке азайган очракта, әлеге алыш-бирешне китереп чыгарган сәбәпләрне (документлар белән расланган) күрсәтергә;<br>2. учреждение администрациясенең опекага алынучы мөлкәте белән алыш-биреш кылуга рөхсәт бирү турында гаризасы (сәбәпләрен күрсәтергә)<br>3. опекага алынган затның дәүләт учреждениесендә булуы (торуы) турында белешмә;<br>4. опека яки попечительлек булдыру һәм опекун яки попечительне билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар, боерык, карар һ.б.);<br>5. гражданны эшкә яраксыз яки чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карары күчермәсе;<br>6. уртак мөлкәтне алуга ризалык турында милекчеләрнең (язмача) гаризасы (әгәр андыйлар булса);<br>7. опекадагы зат исеменә милеккә хокук алучыларның сату-алу (алмашу, бүләк итү һ. б.) шартнамәсе төзү турында язма рәвештә гариза<br>8. саклык кенәгәсе (опекагадагы зат исеменә ачыла, килешү башкарылганнан соң акчалата сумма кертелә), опекадагы затның мөлкәтен аңа башка торак сатып алмыйча читләштергән очракта (стационар социаль тәэмин ителештә психоневрология тибындагы интернат-йортта яшәгәндә; сәламәтлеге торышы буенча мөлкәтне яшәү өчен куллану мөмкин булмаганда);<br>9. сатыла торган һәм сатып алына торган торакка техник паспорт күчермәсе;<br>10. опекадагы затның сәламәтлеге торышы һәм аның мөстәкыйль яшәве мөмкин булмавы турында медицина бәяләмәсе;<br>11. опекадагы затның, шулай ук опекадагы зат исеменә сатып алына торган мөлкәтнең бәясе | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ;<br>№ 8- ТРЗ |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы | Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) опекага алынган затның (эшкә яраксыз | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | затның) милке турында мәгълүмат | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелмәгән;<br>опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу | РФ ГК; № 48-ФЗ; № 8- ТРЗ |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итәлә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Д әүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү турында боерык бирү мәсьәләләре буенча опекун һәм попечительләргә мәгълүмат һәм консультация бирү;

- гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

- бирелгән документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигезләр билгеләү өчен, әлеге Административ регламентта каралган таләпләргә туры килүгә тикшерү үткәрү;

- Бердәм дәүләт хокук реестрыннан (Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте идарәсе) опекага алынган затның (эшкә яраксыз затның) милке турында сорату;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы әлеге Административ регламентның кушымтасында күрсәтелгән.

3.2. Консультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү турында боерык бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән опекага алынган затның хокуклы вәкилен таныштыра;

- опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү турында боерык бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм анлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- алыш-биреш ясауга рөхсәт алу өчен опекун (попечитель) биргән кирәкле документларның булуын тикшерә; кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- докуменлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

Әлеге регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында сорату җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында җибәрелгән сорату.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы опека һәм попечительлек бүлеге органнары соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларның ведомствоара электрон хезмәттәшлеге аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган белешмәләр булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары соратулары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә опекага алынган затның милке белән алыш-биреш ясауга рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

| биналарга таләпләр | биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (унайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча опекуннарга һәм попечительләргә мәгълүмат һәм консультация бирү;

- гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

- бирелгән документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигезләр билгеләү өчен, әлеге Административ регламентта каралган таләпләргә туры килүгә тикшерү үткәрү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы әлеге Административ регламентның кушымтасында күрсәтелгән.

3.2. Консультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән опекага алынган затның хокуклы вәкилен таныштыра;

- опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- опекун (попечитель) биргән кирәкле документларның булуын тикшерә; кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- докуменлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.3.1. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен шәхси җавап тота.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы житәкчесенә раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү турында боерык, 3.7. пункты нигезендә әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.4. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклау вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;
- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенен, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**

**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 95 номерлы карарына 9 кушымта

**Опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча теркәү учетыннан төшерү өчен опекунга (попечительгә) рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар (опекун яки попечитель).

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе (алга таба - РФ Конституциясе) (РФ законнар җыелмасы, 26.01.2009, № 4, 445 ст.);
- 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);
- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба - 3185-I номерлы РФ Законы) («Халык депутатлары Советы һәм Россия Федерациясе Югары Советы ведомостьлары», 20.08.1992, № 33, 1913 ст.);
- «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 152-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31 (1к), 3451 ст.);
- «Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);
- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) (Татарстан Республикасы, № 43-44, 02.03.2004);
- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-

ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.);

- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – м униципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү | РФ ГК; № 48-ФЗ; № 8-ТРЗ; |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | Устав, № 8- ТРЗ |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Опекага алынган затның мирас хокукларына керергә опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү боерык формасында, яисә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | № 48-ФЗ; № 8- ТРЗ; БК турында нигезләмә |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә конкрет чыгымнарны күрсәтеп, акчалардан файдалану турында хисап бирү шарты белән (мөмкин булса - счет, чекларның күчермәләре) опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирүгә опекун яки попечитель гаризасы;<br>2. опека яки попечительлек булдыру һәм опекун яки попечитель билгеләү турында хокукый акт күчермәсе (карар);<br>3. гражданны эшкә яраксыз (чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз) дип тану турында законлы көченә кергән суд органы карарының күчермәсе;<br>4. опекага алынган затның саклау кенәгәсе күчермәсе | РФ ГК;<br>№ 48-ФЗ; |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документлар таләп ителм | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелмәгән;<br>опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу | № 48-ФЗ;<br>№ 8- ТРЗ |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы | |

| | | |
|---|---|---|
| | шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (унайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча опекуннарга һәм попечительләргә мәгълүмат һәм консультация бирү;
- гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;
- бирелгән документларны кабул итү яки баш тарту өчен нигезләр билгеләү өчен, әлеге Административ регламентта каралган таләпләргә туры килүгә тикшерү үткәрү;
- дәүләт хезмәте күрсәтү яки күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы әлеге Административ регламентның 3-нче кушымтасында күрсәтелгән.

3.2. Консультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен жайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән опекага алынган затнын хокуклы вәкилен таныштыра;

- опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- опекун (попечитель) биргән кирәкле документларның булуын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә.

- докуменлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр башкаруның максималь вакыты 15 минут тәшкил итә.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.4. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү проекты әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга опекунга яки попечительгә рөхсәт бирү, 3.7. пункты нигезендә әзерләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.4. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы житәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамлану вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга жибәрү.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы житәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны житкерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;
- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге житәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:
1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 985 номерлы карарына 10 кушымта

**Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда торучы эшкә сәләтсез гражданнарны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү буенча**
**дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда торучы эшкә сәләтсез гражданнарны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү буенчадәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәтне алучылар: суд тәртибендә эшкә сәләтсез дип танылган балигъ булган гражданны вакытлыча кабул итәргә теләгән Россия Федерациясенең балигъ булган гражданнары (алга таба-мөрәҗәгать итүчеләр).

1 1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар (опекун яки попечитель).

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- РФ Конституциясе, 12.12.1993 (алга таба – РФ Конституциясе) (РФ Законнар җыентыгы, 26.01.2009, № 4, 445 м.);
- ТР Конституциясе, 06.11.1992 (алга таба – ТР Конституциясе) (Республика Татарстан, № 87-88, 30.04.2002);
- РФ Гаилә кодексы, 29.12.1995, № 223-ФЗ (алга таба – РФ Гаилә кодексы) РФ Законнар җыентыгы, 01.01.1996, № 1, 16 м.);
- РФ Гражданнар кодексы;
- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 м.);
- «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнар хокукларының гарантияләре турында» РФ Законы, 02.07.1992, № 3185-1 (алга таба –3185-1 санлы РФ Законы) («Ведомости Совета народных депутатов и Верховного Совета Российской Федерации», 20.08.1992, № 33, 1913 м.);
- «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль закон, 21.11.2011, № 323-ФЗ (алга таба – 323-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 28.11.2011, № 48, 6724 м.);
- «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү турында» Федераль закон, 02.08.1995, № 122-ФЗ (алга таба –122-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы,07.08.1995, № 32, 3198 м.);
- «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль закон, 02.05.2006, № 59-ФЗ (алга таба – 59-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 08.05.2006, № 19, 2060 м.);
- «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон, 27.07.2006, 152-ФЗ (алга таба – 152-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 2006, № 31 (1 өл.), 3451 м.);
- «Опека һәм попечительлек турында» Федераль закон, 24.04.2008, № 48-ФЗ (алга таба – 48-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 28.04.2008, № 17, 1755 м.);
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон) (РФ Законнар җыентыгы, 06.10.2003, № 40, 3822 м.);

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» ТР Законы, 27.02.2004, № 8-ТРЗ (алга таба – 8-ТРЗ санлы ТР Законы ) (Республика Татарстан, № 43-44, 02.03.2004);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында», 20.03.2008, № 7-ТРЗ (алга таба – 7-ТРЗ санлы РТ Законы) (Республика Татарстан, № 60-61, 25.03.2008);

- «Балигъ булган эшкә сәләтсез балаларга яки өлешчә эшкә сәләтле булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек алып баруның аерым мәсьәләләре турында» РФ Хөкүмәте карары, 17.11.2010, № 927;

- «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» ТР Министрлар Кабинеты карары, 02.11.2010, № 880 (алга таба – ТР МК 880 санлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 м.);

- «Татарстан Республикасы дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Министрлар Кабинеты карары, 18.06.2007, № 245 (алга таба – ТР МК 245 санлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 11.07.2007, № 25-26, 0916 м.);

- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларда торучы эшкә сәләтсез гражданнарны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында бәяләмә бирү | РФ ГК; РФ Гаилә кодексы; 48-ФЗ санлы Федераль закон; 927 нче РФ Хөкүмәте карары; 8-ТРЗ санлы ТР Законы |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | Устав;<br>7-ТРЗ санлы ТР Законы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Язма формада бәяләмә яки баш тату турында хат | РФ ГК; РФ Гаилә кодексы; 48-ФЗ санлы Федераль закон; 927 нче РФ Хөкүмәте карары; 8-ТРЗ санлы ТР Законы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Язма формада бәяләмә яки баш тату турында хат гариза кергәннән соң 15 көн эчендә бирелергә тиеш | 48-ФЗ, 210-ФЗ санлы Федераль закон; 927 нче РФ Хөкүмәте карары |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Гариза.<br>2. Паспорт күчермәсе.<br>3. Медицина бәяләмәсе.<br>4. Гражданны эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләте чикләнгән дип тану турында суд карары<br>Документларның төп нөсхәләре һәм күчермәләре бирелә (исемлектән соң төп нөсхәләре кире кайтарыла), документларның нотариаль таныкланган күчермәләрен кабул итү мөмкин. | РФГК; РФНК;<br>48-ФЗ, 210-ФЗ санлы Федераль закон; 927 нче РФ Хөкүмәте карары |
| 2.6. Дәүләт органнары, жирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соралырга мөмкин:<br>- яшәү урыныннан йорт (фатир саен) кенәгәсеннән өземтә яки торак урыныннан файдалану хокукын яки торак урынына милек хокукын раслый торган башка документ;<br>- яшәү урыныннан финанс шәхси счет күчермәсе;<br>- ул эшкә сәләтсез яки чикләнгән эшкә сәләтсезне гаиләгә кабул итәргә теләк белдергән гражданның хөкем ителмәвен раслаучы эчке эшләр органнары белешмәсе;<br>- эшкә сәләтсез затка карата аның диагнозы өй шартларында яшәү өчен туры килүе турында бәяләмә | 210-ФЗ санлы Федераль закон |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, жирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>- тапшырылган документларның билгеләнгә таләпләргә туры килмәве;<br>- гариза бирүче тарафыннан әлеге регламентта каралган дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның тулы комплекты тәкъдим ителмәгән;<br>- мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр бар;<br>- мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | 927 нче РФ Хөкүмәте карары |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>әгәр гариза бирүче түбәндәге категориягә карый:<br>- суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки эшкә сәләте чикләнгән дип танылган затлар;<br>- закон тарафыннан йөкләнгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) вазыйфаларыннан читләштерелгән затлар;<br>- хөкем ителгән яки җинаять җаваплылыгына тартылган;<br>- ачык формада йогышлы авырулар яки психик авырулар, наркомания, токсикомания, алкоголизм белән авыручы затлар;<br>- Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү урыны | РФ ГК; РФ Гаилә кодексы; 48-ФЗ санлы Федераль закон; 8-ТРЗ санлы ТР Законы |

| | | |
|---|---|---|
| | булмаган затлар.<br>Гариза бирүче тарафыннан дөрес тутырылмаган яки үз көчен югалткан документларны тапшыру | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. Чиратта көтүнең максималь вакыты 30 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

консультация бирү;

- гариза кабул итү һәм теркәү;

- дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү, гариза бирүченең торак-көнкүреш шартларын (кушымта) тикшерү һәм документларны эшкәртү;

- дәүләт хезмәте күрсәтү яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү;

- гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү яки гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат җибәрү, социаль учреждениедә булган эшкә сәләтсез затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләү.

3.1.2. Гражданның опека һәм попечительлек бүлегенә консультация сорап мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора. Опекун белгечкә паспорт яки шәхесен раслаучы башка документны күрсәтә.

Белгеч:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- д әүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән таныштыра, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту сәбәпләре турында аңлата;

- кирәкле документлар исемлеген бирә;

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза язу формасы турында аңлата.

Консультация мөрәҗәгать итү көнендә үткәрелә.

Гариза бирүчегә документлар рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтү таләп ителми.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла: гаризалар һәм документлар 15 минут эчендә кабул ителә; гариза кергән вакыттан бер көн эчендә теркәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Мөрәҗәгать итүче үзе хезмәт күрсәтү турында язма гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Белгеч әлеге административ регламент нигезендә кирәкле барлык документларның комплектлылыгын һәм булуын тикшерә, шул исәптән:

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели;
- тәкъдим ителгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;
- документларны тутыруның дөреслеген тикшерә;
- документларнын текстлары аңлаешлы язылганын һәм карандаш белән язылмаганлыгын билгели;
- документларда сызылган сүзләр, төзәтүләр булмауны, документларга зыян килмәүне тикшерә;
- документларны терки;
- муниципаль берәмлек Башкарма комитетының опекун комиссиясенә бирү өчен документлар пакетын әзерли.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч, конфиденциаль мәгълүматларны исәпкә алып, документларны кабул итү процедураларының дөрес башкарылуы өчен җавап бирә.

Бүлек белгечләре конфиденциаль мәгълүматтан рөхсәтсез файдалануны һәм әлеге мәгълүматны алу хокукы булмаган затларга аны (яки) тапшыруны булдырмаска бурычлы.

Опека һәм попечительлек бүлегендәге конфиденциаль мәгълүматның сакланышын тәэмин итү максатында, белгечләргә әлеге мәгълүматны башка затларга тапшыру тыела.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гаризаларны журналда теркәү, расписка яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.1. Белгеч дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга яшәү урыныннан йорт кенәгәсеннән (фатир буенча) өземтә, яки торак урыннан файдалану хокукын раслый торган башка документны, яки торак бинага милек хокукы һәм яшәү урыныннан финанс шәхси счет күчермәләрен алу максаты белән, ведомствоара запрослар формалаштыра һәм юнәлтә.

3.4. Кирәкле документлар булмау, бирелгән документларнын регламент таләпләренә туры килмәве, гаризада яки бирелгән документларда булган белешмәләрнең дөрес булмавы яки опекуннан документлар кабул иткәндә гаризада кирәкле мәгълүматлар булмавы ачыкланган очракта, белгеч дәүләт хезмәте күрсәтү өчен ачыкланган каршылыклар исемлеген төзи һәм аны гариза бирүчегә документлар белән бергә тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: запроска җавап яки мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче җитмәгән яки төзәтелмәгән, яки тиешенчә рәсмиләштерелгән документларны тапшыру белән килешмәсә, яки аларны бирү мөмкин булмаганда, шулай ук баш тарту өчен башка нигез булганда, белгеч дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында язмача мотивацияләнгән җавап әзерли.

3.4.2. Баш тарту турында кул куелган хәбәрнамә мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла яки тиешле карар кабул ителгән көннән соң 5 эш көне эчендә почта аша җибәрәрә.

3.5. Белгеч опекун комиссиясенә бирү өчен документлар пакетын формалаштыра.

Опека һәм попечительлек комиссиясе утырышта социаль учреждениедә булган эшкә сәләтсез затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү мәсьәләсен карый.

Опекун комиссиясенең утырыш нәтиҗәсе булып беркетмә белән рәсмиләштерелә торган һәм опекун комиссиясе рәисе, әгъзалары тарафыннан имзалана торган карар кабул итү тора.

Комиссия утырышы документлар кергән саен үткәрелә. Комиссия карарлары нәтиҗәләре буенча опекун комиссиясе утырышы беркетмәсеннән өземтә чыгарыла.

Социаль учреждениедә стационар хезмәт күрсәтүдә булган балигъ булмаган гражданны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнар гаиләләренә тапшырганда, опека һәм попечительлек органы:

- птапшырылган документларны тикшерә;
- гражданинның һәм аның гаиләсенең тормыш шартларын тикшерә, гражданинның тормыш-көнкүреш шартларын бәяләү максатында һәм гражданның гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклап, акт рәсмиләштерә..

3.6. Дәүләт хезмәте КФҮ, КФҮнең ерактан торып эш урыны аша күрсәтелми.

3.7. Техник хаталарны төзәтү

3.7.1. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче бүлеккә тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза;

гариза бирүчегә техник хата булган хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

3.7.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итә, документлар белән гаризаны терки һәм аларны бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белгечкә карауга юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Белгеч документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында, әлеге регламентнын 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтелгән документны, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның оригиналын алып, кул куйдырып бирә яки мөрәҗәгать итүчегә, белгечкә техник хата булган документ оригиналын тәкъдим иткәндә, почта аша (электрон почта аша) документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, техник хаталар ачыкланганнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан хата турында гариза алганнан соң, өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнен хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, жирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтижәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә жаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнен тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге житәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренен җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт к үрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәжәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәжәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәжәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәжәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтижәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтижәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган житәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган житәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәжәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәжәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**
**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 185 номерлы карарына 11 кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);

- «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында» 2009 елның 19 маендагы 432 номерлы РФ Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү Кагыйдәләре (алга таба - 432 номерлы Кагыйдәләр) РФ законнары җыелмасы, 25.05.2009, № 21, 2581 ст.);

- «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 19 маендагы 432 номерлы карарын гамәлгә ашыру турында» 2009 елның 18 июнендәге 212 номерлы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы (алга таба - 212 номерлы боерык)

- «Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 26.05.2004, № 21, 2021 бит);

- «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008, «Татарстан Дәүләт Советы ведомостьлары», 2008, № 3, 212 ст.);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880-нче карары;
- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);
- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);
- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);
- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү | 432 номерлы Кагыйдәләр |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Язмача рөхсәт яки баш тарту турында хат формасында опека һәм попечительлек бүлегенең бәяләмәсе | 432 номерлы Кагыйдәләр |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | 432 номерлы Кагыйдәләр |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. гариза (1нче кушымта);<br>2. шәхесне раслаучы паспорт яисә башка документ күчермәсе (оригиналын күрсәткән очракта);<br>3. гражданда авырулар булмау турында дәвалау- профи лактика учреждениесе белешмәсе (медицина бәяләмәсе).<br>4. граждан балаларны тәрбияләүдә кирәкле белем һәм күнекмәләр булуын, шул исәптән белеме турында, һөнәри эшчәнлек, опекунлыкка яки попечительлеккә кандидатлар әзерләү программаларын узуын раслаучы башка доку-ментларны тапшырырга хокуклы | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары 1716 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына: Опека һәм попечительлек органы гариза бирелгән көннән алып 2 эш көне эчендә тиешле вәкаләтле органнардан гражданның Россия Федерациясе Гаилә кодексының 146 статьясы 1 пункты өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән хәлләрнең булмавын раслый торган белешмәләрне раслауны соратып ала. Ведомствоара гаризнамә ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын һәм аңа тоташа торган ведомствоара электрон багланышларның региональ системаларын кулланып, электрон докмент формасында җибәрелә. Опека органы гаризнамәсенә һәм әлеге пунктның дүрт абзацында каралган белешмәләрне раслау турында попечительлек бирүнең рәвеше һәм тәртибе, шулай ук опека һәм попечительлек органының тиешле гаризнамәсе рәвеше Россия Федерациясе Эчке эшләр | 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон 1716 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | министрлыгы тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән белешмәләрне раслау турындагы җавап опека һәм попечительлек органына 5 эш көне эчендә җибәрелә | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Опека һәм попечительлек органына гариза белән мөрәҗәгать иткән граждан(нар)га дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга мөмкин, әгәр мөрәҗәгать итүче(ләр) түбәндәге категориягә кергән очракта:<br>а) суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип танылган затлар;<br>б) суд буенча ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокуклары чикләнгән затлар;<br>в) элеккеге уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу алар гаебе белән суд буенча гамәлдән чыгарылган булса;<br>г) закон тарафыннан йөкләнгән бурычларын тиешенчә үтәмәгән өчен, опекун (попечитель) бурычларыннан азат ителгән затлар;<br>д) аларның гаиләсенә баланы (балаларны) вакытлыча тапшыру вакытына гражданнар тормышына һәм сәламәтлегенә каршы белә торып җинаять кылган өчен хөкем ителгән затлар;<br>е) наркомания, токсикомания, алкоголизм белән авыручы, ачык формада йогышлы авырулары яисә психик авырулары булган затлар;<br>ж) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәү урыны булмаган атлар.<br>2. Тапшырылган документларның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>3. Алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү хокукы билгеләнә торган мөрәҗәгать итүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган | 432 номерлы Кагыйдәләр |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) мөрәҗәгать итүчене һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5. п. кара);

3) мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү (2-нче кушымта);

4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм җибәрү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерү;

6) Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләү;

7) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү (3-нче кушымта);

8) мөрәҗәгать итүчегә нигез булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү (җибәрү).

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 5-нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Консультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү мәсьәләләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәртибе белән опекунны таныштыра;

- Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- кирәкле документларның булуын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече, КФҮ (КФҮ аша хезмәт күрсәтү шарты белән) мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.4. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм бәяләмәне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында сорату җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында сорату.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан опека һәм попечительлек бүлеге соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларның ведомствоара электрон хезмәттәшлеге аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта, соратып алына торган мәгълүматлар бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары соратулары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.6. Мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүченең торак- көнкүреш шартларын, мотивларын, бала тәрбияләүгә сәләтен, мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрен тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең торак-көнкүреш шартларын тикшерү.

3.6.2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул тикшерү уздырган затларның имзалары белән раслана һәм бүлек Җитәкчесе тарафыннан раслана.

Гражданинның тормыш шартларын тикшергәндә, баланың тормышына һәм сәламәтлегенә, аның физик һәм әхлакый үсешенә куркыныч тудыручы яисә тудыра ала торган яки аның хокукларын һәм закон белән саклана торган мәнфәгатьләрен боза яки бозачак шартлар ачыкланса, опека һәм попечительлек органы гражданнан өстәмә рәвештә язма формада соратып алырга хокуклы:

а) гражданның бала вакытлыча булачак торак урынга файдалану хокукын яки милек хокукын раслый торган документлар күчермәләре;

б) дәвалау-профилактика оешмасының граждан белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының ачык формада йогышлы авырулары һәм психик авырулары булмавы турында белешмәсе. Белешмә урынына гражданинның гаилә әгъзалары дәвалау- профилактика учреждениесе биргән медицина нәтиҗәсен тәкъдим итә алалар. Күрсәтелгән документлар аларны бирү датасыннан алып 6 ай эчендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан кабул ителә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзенә балаларны вакытлыча тапшыру турында теләк белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү актын төзү (әлеге Регламентка 2-нче кушымта) яисә мөрәҗәгать итүчедән 3.6.2. пунктының «а» һәм (яки) «б» пунктчаларында каралган документларны язмача сорату.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү проекты әзерли һәм

аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә килештерүгә һәм раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Граждан яшәү урыны буенча торак бина тиешле торак пункт шартларына карата уңайлыклары булмаган очракта яисә баланың күрсәтелгән торак урынында булуы аның сәламәтлегенә, физик һәм әхлакый үсешенә куркыныч тудырса, граждан яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы гражданга әлеге торак урынында тормыйча гына бала (балаларны) вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә рәсмиләштерергә хокуклы. Шул ук вакытта гражданинга мөмкин:

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешманың көн тәртибе нигезендә көндезге сәгатьләрдә баланы (балаларны) алырга;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасына туристик путевка күрсәтеп, бала (балалар) белән шифаханә-курорт дәвалавы һәм ял итү объектлары, дәвалау-сәламәтләндерү, физкультура-спорт һәм башка билгеләнештәге объектлар территорияләрендә урнашып, ял итү (сәламәтләндерү) өчен чыгу;

граждан яшәү урыны булмаган торак бинада бала (балалар) белән тору.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган граждannар гаиләләренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны вакытлыча бирү мөмкинлеге турында бәяләмә, яисә 3.9. пункты нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат.

3.8. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.8.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.1. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.9. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.9.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту нигезләрен ачыклаган вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.9.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.9.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.9.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамла-ганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.
Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:
- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;
- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт к үрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**

**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 985 номерлы карарына 12 кушымта

**Балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү буенча теркәү учетыннан төшерү өчен опекунга (попечительгә) рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);
- елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Гаилә кодексы (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 01.01.1996, № 1, 16 ст.);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31-нче номерлы 4179 ст.);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба - ТР ГК) (2009 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы Татарстан Республикасы);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТРЗ) (2004 елның 2 мартындагы 43-44 номерлы Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары җыентыгы һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары, 26.05.2004, № 21);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880-нче карар;

- Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

- Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

- Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү | РФ ГК 28, 37 ст.;<br>№ 48-ФЗ 21 ст. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | № 8-ТРЗ |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен Боерык формасында алдан рөхсәт бирү яки хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ ГК 28, 37 ст.;<br>№ 48-ФЗ 21 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | № 48-ФЗ 21 ст. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Ике ата-ананың (яки аларны алыштыручы затларның) гаризасы (1нче кушымта).<br>2. Ата-аналарның (аларны алыштыручы затларның) паспортлары.<br>3. Балигъ булмаганнарның паспортлары. Оригиналлары булган очракта, документларның күчермәсе 1 нөсхәдә бирелә | РФ ГК 28, 37 ст.;<br>№ 48-ФЗ 21 ст. |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан кирәкле документлар:<br>1. Балигъ булмаганнарны теркәү урыны буенча йорт кенәгәсеннән һәм финанс-лицевой счеттан өземтә.<br>2. Милекчесе булып балигъ булмаган зат торган торак бинага хокук билгеләге торган документлар.<br>3. Балалар туу турында таныклык | № 210-ФЗ |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | РФ ГК 28, 37 ст.;<br>№ 48-ФЗ 21 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>- тапшырылган документларның әлеге административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>- опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу. | РФ ГК 28, 37 ст.; № 48-ФЗ 21 ст. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәплəү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | № 210-ФЗ |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | № 210-ФЗ от |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | № 210-ФЗ |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар; | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гариза һәм документларны кабул итү;

3) балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирүне әзерләү яки баш тарту турында хат;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү;

5) мөрәҗәгать итүчегә нигез булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 3нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Конс ультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән опекага алынган затның хокуклы вәкилен таныштыра;

- балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту өчен алдан рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

3.3. Гариза, док ументларны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны һәм гаризаны шәхсән опека һәм попечительлек бүлегенә, КФҮнә (хезмәт күрсәтү КФҮ аша бирелсә) бирә.

3.3.2. Кабул итүне алып баручы опека һәм попечительлек бүлеге, КФҮ белгече гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын ачыклый;

документларның булу-булмавын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече, КФҮ мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.3.3. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

3.3.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәтне әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү

3.4.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында сорату җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында сорату.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан опека һәм попечительлек бүлеге соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;
- соратып алына торган мәгълүматларның ведомствоара электрон хезмәттәшлеге аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары соратулары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тарту турында боерык проекты әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә килештерүгә һәм раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: балигъ булмаган(нар) исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга рөхсәт бирү турында боерык, яисә 3.7. пункты нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.5.1. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли (алга таба - баш тарту турында хат).

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тартуга нигезләр табылган вакыттан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамла-ганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм

муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәннераслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**

**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 985 номерлы карарына 13 кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алуга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алуга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Гаилә кодексы (алга таба - Р Ф ГК) (РФ законнар җыелмасы, 01.01.1996, № 1, 16 ст.);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасынын 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба - ТР ГК) (2009 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы Татарстан Республикасы);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТРЗ) (2004 елның 2 мартындагы 43-44 номерлы Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары җыентыгы һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары, 26.05.2004, № 21);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 карары;

Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алуга кандидат буларак исәпкә кую | РФ Гаилә Кодексы 19 бүлек<br>ТР Гаилә Кодексы 19 бүлек<br>РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | РФ Гаилә Кодексы 19 бүлек<br>ТР Гаилә Кодексы 19 бүлек<br>7-ЗТР номерлы ТР законы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Уллыкка алуга кандидат була алу турында бәяләмә әзерләү һәм уллыкка алуга кандидат буларак исәпкә кую | РФ Гаилә Кодексы 19 бүлек |

| | | |
|---|---|---|
| | | ТР Гаилә Кодексы 19 бүлек<br>РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | - Россия Федерациясе гражданнары, уллыкка алучыларга кандидат булу һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә алу мөмкинлеге турында бәяләмә алырга теләгән гражданнар яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына тапшыралар:<br>- баланы уллыкка (кызлыкка )алырга теләүче затларны исәпкә кую турында язма гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта),<br>- үз гаиләсенә тәрбиягә бала алырга теләүче граждан анкетасы (әлеге Регламентка 2 нче кушымта),<br>- паспорт яки шәхесне таныклаучы башка документ, түбәндәге документлар белән:<br>- 1) кыскача автобиография;<br>- 2) вазыйфа һәм хезмәт хакы күрсәтелгән эш урыныннан белешмә яки керемнәр турында декларациянең күчермәсе;<br>- 3) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы билгеләгән тәртиптә рәсмиләштерелгән баланы уллыкка алырга теләүче затның сәламәтлеге торышы турында дәүләт яисә муниципаль дәвалау-профилактика учреждениесенең медицина бәяләмәсе;<br>- 4) Россия Федерациясе Гаилә кодексының 127 статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән тәртиптә (баланың якын туганнарыннан, шулай ук уллыкка алу юкка чыгарылмаган һәм уллыкка алынмаган затлардан һәм балаларның опекуннары (Попечительләр) булып торучы яисә үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдән читләштерелгән затлардан тыш) үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү узу турында таныклык күчермәсе. Әлеге таныклыкның формасы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан раслана.РФ Гаилә Кодексының 127 ст. пунктында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләүче затларны әзерләү турында таныклык күчермәсе (якын туганнарыннан тыш, шулай ук уллыкка алучылар яки алучылар булып торган һәм аларга карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан тыш, һәм баланың опекуны (попечителе) булучылар яки булып торган һәм аларга йөкләнгән бурычларын үтәүдән азат ителмәгән затлардан тыш).<br>Әлеге пунктның 2-4 пунктларында санап үтелгән документлар аларны биргән көннән ел дәвамында гамәлдә була, ә медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында бәяләмә - 6 ай дәвамында. Документларның күчермәләре ике нөсхәдә | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | оригиналлар булганда тапшырыла. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Опека һәм попечительлек органы гариза биргән көннән 2 эш көне эчендә тиешле органнардан гаризада күрсәтелгән белешмәләрне раслауны, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан ихтыяҗ булырга мөмкин булган документларны соратып ала:<br>1.Уллыкка алырга теләүче гражданнын яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр;<br>2. Гражданда Россия Федерациясе Гаилә кодексынын 127 статьясы 1 пункты 9 - 11 пунктчаларында күрсәтелгән шартлар булмавын раслаучы белешмәләр; опека һәм попечительлек органынын белешмәләрне раслау турындагы соравына җавап бирү рәвеше һәм тәртибе, шулай ук опека һәм попечительлек органынын тиешле запрос формасы Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән белешмәләрне раслау турындагы җавап тиешле запрос алынганнан соң 5 эш көне эчендә опека һәм попечительлек органына җибәрелә.<br>3. Алына торган пенсия, анын төре һәм күләме (төп керем чыганагы-мәҗбүри пенсия иминияте буенча иминият тәэминаты яки башка пенсия түләүләре булган затлар өчен)турында белешмәләр<br>4. өйләнешү турында таныклык күчермәсе (әгәр торалар никахта)<br><br>Ведомствоара запрос электрон документ рәвешендә, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон бәйләнешнең региональ системаларын кулланып җибәрелә.<br>Граждан әлеге Административ регламентта күрсәтелгән документларның күчермәләре тапшырылмаган очракта, опека һәм попечительлек органы күрсәтелгән документларның күчермәләрен мөстәкыйль әзерли (граждан тарафыннан тапшырылган әлеге документларның төп нөсхәләре булганда).<br>Гражданнар әлеге Административ регламентның 2.5 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацлары нигезендә гаризада күрсәтелгән белешмәләр бер ел элек расланган булса, баланың (балаларның) яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органы мондый белешмәләрне раслау өчен тиешле вәкаләтле органнардан кабат соратып ала.<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге регламентның 2.5 пункты белән документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Күрсәтелгән документлар, бирелгән мәгълүматның конфиденциальлеген саклау максатларында, мөрәҗәгать | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | итүченең алдан ризалыгы белән, опека һәм попечительлек органы тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алына.<br>Вәкаләтле орган тарафыннан белешмәләрне раслау турында опека һәм попечительлек органы сорауларына җаваплар тиешле запрос алынганнан соң 5 көн эчендә опека һәм попечительлек органына җибәрелә.<br>Күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырганда уллыкка алу сере саклансырга тиеш. Аны хәл итү өчен гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әгәр мөрәҗәгать итүче(ләр) түбәндәге категориягә карасалар:<br>1) суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип танылган затлар;<br>2) суд тарафыннан берсе эшкә яраксыз яки чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип табылган ир белән хатын; суд буенча ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукларында суд чикләгән затлар;<br>3) закон йөкләгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) бурычларыннан азат ителгән затлар;<br>4) элеккеге уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу аларның гаебе белән суд тарафыннан гамәлдән чыгарылган булса;<br>5) сәламәтлеге буенча баланы уллыкка ала алмаган затлар. Бу авырулар булганда, кеше баланы уллыкка, опекага, попечительлеккә,тәрбиягә яки патронат гаиләгә ала алмый торган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;<br>6) уллыкка алган вакытта уллыкка алган балага Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы тәэмин итүче keremгә ия булмаган затлар;<br>7) даими яшәү урыны булмаган затлар;<br>8) шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы җинаять эзәрлекләвенә дучар ителә торган яки дучар ителгән, хөкем ителә торган яки хөкем ителгән затларга (аларга карата реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), шулай ук шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз | РФ Хөкүмәтенең 275 номерлы карары; РФ Гаилә Кодексының 127 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаган балаларга, халык саулыгына һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, 10 пунктта каралган очраклардан тыш, җәмәгать куркынычсызлыгына, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы җинаять кылган өчен;<br>кечкенә һәм уртача авырлыктагы җинаятьләргә караган, 9 пунктта күрсәтелгән затлар арасыннан хөкем ителгән яки шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаган балаларга, халык саулыгына һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, җәмәгать куркынычсызлыгына, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы җинаять кылган өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар ителгән затлар, әгәр суд тарафыннан уллыкка алынган баланың тормышы, сәламәтлеге һәм әхлагына куркыныч тудыра торган затлар дип танылган очракта;<br>11) 9 пунктта күрсәтелгән җинаятьләргә кагылмаган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән затлар;<br>12) РФ Гаилә кодексының 116 статьясындагы 6 - 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (якын туганнарыннан тыш, шулай ук уллыкка алучылар яки алучылар булып торган һәм аларга карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан тыш, һәм баланың опекуны (попечителе) булучылар яки булып торган һәм аларга йөкләнгән бурычларын үтәүдән азат ителмәгән затлардан тыш);<br>13) элеге өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә никах дип танылган һәм теркәлгән бер җенес вәкилләре арасында төзелгән берлектә торучы затлар, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булган һәм никахта булмаган затлар;<br>14) хроник алкоголизм яки наркомания белән авыручы затлар, опекун (Попечительләр) вазыйфаларын үтәүдән читләштерелгән затлар, ата-ана хокукларында чикләнгән затлар, уллыкка алучылар (уллыкка алучылар) билгеләнмиләр, әгәр алар гаебе белән баланы уллыкка алу гамәлдән чыгарылса.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бирү, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү хокукы билгеләнә.<br>2. Тапшырылган документларның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>Дәүләт хезмәтен туктату өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | № 210-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | № 210-ФЗ от |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | № 210-ФЗ |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Уллыкка алуга кандидат була алу турында бәяләмә әзерләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гариза (1-нче кушымта) һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5. п. кара);

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара сорату формалаштыру һәм җибәрү;

4) уллыкка алуга кандидат була алу турында бәяләмә әзерләү һәм исәпкә кую (3-нче кушымта);

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү;

6) мөрәҗәгать итүчегә нигез булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 5-нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. М өрәҗәгать итүчегә консультация бирү

Гариза бирүче дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе турында консультация алу өчен опека һәм попечительлек бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать итә.

Опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлеге һәм формасы буенча да.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документлар исемлеге һәм формасы буенча консультацияләр, аңлатмалар.

3.3. Гариза, док ументларны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, 2.6 пунктында күрсәтелгән документлардан тыш (гариза бирүче белән килешү буенча), 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, гаризаны шәхсән бирә.

3.3.2. Кабул итүне алып баручы опека һәм попечительлек бүлеге белгече мөрәҗәгать итүченең шәхесен, яшәү урынын ачыклый.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документы яки гариза бирүче тиешле органга мөрәҗәгать итмәгән очракта, гариза һәм документлар кабул итүдән баш тарталар.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесе һәм тиешле органга мөрәҗәгатене расланган очракта, опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза һәм аңа кушып бирелә торган документларны кабул итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.3.3. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар.

3.3.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, опека һәм попечительлек бүлеге белгече баш тарту турында хат әзерли һәм гариза бирүчегә кул куелган көннән алып 2 көн эчендә мәгълүматын җиткерә. Бер үк вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карар өстеннән шикаять бирү тәртибе аңлатыла һәм әлеге Регламентның 3.6 пунктында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм бәяләмә әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында сорату җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында сорату.

3.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан опека һәм попечительлек бүлеге соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларның ведомствоара электрон хезмәттәшлеге аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтел, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары соратулары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Уллыкка алуга кандидат була алу турында бәяләмә әзерләү

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгечләре уллыкка алуга кандидат була алу мөмкинлеге турында бәяләмә әзерләү өчен мөрәҗәгать итүченен торак-көнкүреш шартларын, аның мотивларын, бала тәрбияләү сәләтен тикшерә; гариза бирүченең гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклый. Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданинның тормыш шартларын тикшерү акты рәсмиләштерелә, ул тикшерү уздырган затларның имзалары белән раслана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, опека бүлеге белгече соратып ала торган мәгълүматларны тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан раслаганнан соң 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: балигъ булмаган затны уллыкка (кызлыкка) алу (әлеге Регламентка 2-нче кушымта) теләген белдергән гражданинның тормыш шартларын тикшерү актын төзү.

3.5.2. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар һәм тикшерү акты нигезендә уллыкка алуга кандидат була алу мөмкинлеге турында бәяләмә яисә уллыкка алуга кандидат була алмау турында хат әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә раслауга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әлеге регламентның 3.4. пункты нигезендә әзерләнгән опека бүлеге белгече соратып ала торган мәгълүматларны тиешле вәкаләтле органнар тарафыннан раслаганнан соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә уллыкка алучы була алу турында бәяләмә бирү, яисә 3.6. пункты нигезендә әзерләнгән баш тарту турында хат (әлеге Регламентка 3-нче кушымта).

3.5.4. Уңай бәяләмә алган очракта, баланы уллыкка (кызлыкка) алырга теләүче затларның гаризалары нигезендә анкета (әлеге Регламентка 4нче кушымта) тутырыла, алар махсуслаштырылган журналда теркәлә һәм шәхсән уллыкка (кызлыкка) алуга кандидатлар тарафыннан Казан шәһәренең Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының уллыкка алу, опека һәм попечительлек үзәгенә «Уллыкка алу» республика мәгълүматлар банкына исәпкә кую өчен кертелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене уллыкка алучыга кандидат сыйфатында исәпкә кую.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат әзерләү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли (алга таба - баш тарту турында хат).

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзага җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектына имзалауга җибәрү.

3.6.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хат проектын имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.6.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүченең кул куелган көннән алып 3 көн эчендә кире кагу турында хат җиткерә. Бер үк вакытта гариза бирүчегә барлык документлар кире кайтарыла һәм карар өстеннән шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт к үрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган житешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**
**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 105 номерлы карарына 14 кушымта

**Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирү дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирү дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Гаилә кодексы (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 01.01.1996, № 1, 16 ст.);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба - ТР ГК) (2009 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы Татарстан Республикасы);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 26.05.2004, № 21);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 карары (алга таба - ТР МК 880 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст.; 20.12.2011, № 48, 2612 ст.; 25.05.2012, № 40, 1252 ст.);

Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирү | РФ ГК 28 ст. РФ ГК 37 ст. РФ Гаилә Кодексы 60 ст. 48-ФЗ номерлы Федераль закон 21 ст. 122-ФЗ номерлы Федераль 8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Рөхсәт документы рәвешендә балигъ булмаган баланыкы булган күчемле милекне читләштерү буенча алыш- бирешләр | 8-ТРЗ номерлы ТР законы 7-ТРЗ номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| | ясауга алдан рөхсәт.<br>Хат рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | ТР законы Устав, ТР ТКМР БК Нигезләмәсе,15.08.2014 |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Мөрәҗәгать итүчедән барлык кирәкле документлар кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә | РФ ГК 37 ст. РФ Гаилә Кодексы 60 ст. 48-ФЗ номерлы Федераль закон 21 ст.<br>8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1. Бер ата-ананың (яки аларны алыштыручы затларның) һәм 14 яше тулган балигъ булмаган затның гаризасы (1нче кушымта).<br>2. Ата-ананың (яки аны алыштыручы затның) паспорт күчермәсе.<br>3. 14 яше тулган балигъ булмаган затның паспорт күчермәсе.<br>4. Читләштерелә торган күчемле мөлкәткә хокук билгеләүче документ.<br>5. Хокукны дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе (булганда).<br>6. Күчемле мөлкәткә техник паспорт күчермәсе.<br>7. Мөрәҗәгать итү вакытына агымдагы елга күчемсез мөлкәткә бәяләү хакы<br>8. Югалткан милек урынына сатып алына торган мөлкәткә документлар (хокук билгеләүче документлар, хокукны дәүләт теркәве турында таныклык (булган очракта), техник паспорт, мөлкәтне бәяләү хакын раслаучы документ) яки баланың читләштерелгән күчемле мөлкәт хакына тигез булган бәягә балигъ булмаган бала исеменә ачылган исәп- хисап счетыннан өземтә.<br>9. Банкта балигъ булмаган бала исеменә счет. Документларның күчермәләре, оригиналлар булганда, 1 нөсхәдә бирелә; документларның нотариаль расланган күчермәләрен кабул итү мөмкин. | 48-ФЗ номерлы Федераль закон 21 ст. |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында белгеч тарафыннан сорала торган кирәкле документлар:<br>- туу турында таныклык | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |

| | | |
|---|---|---|
| баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әгәр мөрәҗәгать итүче(ләр) түбәндәге категориягә карасалар:<br>1) суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип танылган затлар;<br>2) суд тарафыннан берсе эшкә яраксыз яки чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип табылган ир белән хатын; суд буенча ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки ата-ана хокукларында суд чикләгән затлар;<br>3) закон йөкләгән бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен опекун (попечитель) бурычларыннан азат ителгән затлар;<br>4) элеккеге уллыкка алучылар, әгәр уллыкка алу аларның гаебе белән суд тарафыннан гамәлдән чыгарылган булса;<br>5) сәламәтлеге буенча баланы уллыкка ала алмаган затлар. Бу авырулар булганда, кеше баланы уллыкка, опекага, попечительлеккә,тәрбиягә яки патронат гаиләгә ала алмый торган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;<br>6) уллыкка алган вакытта уллыкка алган балага Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы тәэмин итүче керемгә ия булмаган затлар;<br>7) даими яшәү урыны булмаган затлар;<br>8) шәхеснең җенси кагылгысызлыгына һәм җенси ирегенә каршы җинаять эзәрлекләвенә дучар ителә торган яки дучар ителгән, хөкем ителә торган яки хөкем ителгән затларга (аларга карата реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), шулай ук шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаган балаларга, халык саулыгына һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, 10 пунктта каралган очраклардан тыш, җәмәгать куркынычсызлыгына, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы җинаять кылган өчен;<br>кечкенә һәм уртача авырлыктагы җинаятьләргә караган, 9 пунктта күрсәтелгән затлар арасыннан хөкем ителгән яки шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә каршы, ирегенә, намусына һәм абруена (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаган балаларга, халык саулыгына һәм иҗтимагый әхлаклылыкка, җәмәгать куркынычсызлыгына, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы җинаять кылган өчен җинаять эзәрлекләвенә дучар ителгән затлар, әгәр суд тарафыннан уллыкка алынган баланың тормышы, сәламәтлеге һәм әхлагына куркыныч тудыра торган затлар дип танылган очракта; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 11) 9 пунктта күрсәтелгән җинаятьләргә кагылмаган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән затлар;<br>12) РФ Гаилә кодексының 116 статьясындагы 6 - 10 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә әзерлек узмаган затлар (якын туганнарыннан тыш, шулай ук уллыкка алучылар яки алучылар булып торган һәм аларга карата уллыкка алу юкка чыгарылмаган затлардан тыш, һәм баланың опекуны (попечителе) булучылар яки булып торган һәм аларга йөкләнгән бурычларын үтәүдән азат ителмәгән затлардан тыш);<br>13) әлеге өйләнешү рөхсәт ителгән дәүләт законнары нигезендә никах дип танылган һәм теркәлгән бер җенес вәкилләре арасында төзелгән берлектә торучы затлар, шулай ук күрсәтелгән дәүләт гражданнары булган һәм никахта булмаган затлар;<br>14) хроник алкоголизм яки наркомания белән авыручы затлар, опекун (Попечительләр) вазыйфаларын үтәүдән читләштерелгән затлар, ата-ана хокукларында чикләнгән затлар, уллыкка алучылар (уллыкка алучылар) билгеләнмиләр, әгәр алар гаебе белән баланы уллыкка алу гамәлдән чыгарылса.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бирү, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү хокукы билгеләнә.<br>2. Тапшырылган документларның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>Дәүләт хезмәтен туктату өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә | |

| | | |
|---|---|---|
| | ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган бинаалар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш- бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гариза һәм документларны кабул итү (әлеге регламентның 2.5. п. кара);

3) тәкъдим ителгән документларны карау;

4) балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирүне әзерләү яки баш тарту турында хат;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү;

5) мөрәҗәгать итүчегә нигез булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 3-нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Консультация бирү.

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән опекага алынган затның хокуклы вәкилен таныштыра;

- балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, опекага алынган затның яшәү урынын ачыклый;

- опекун (попечитель) тарафыннан бирелгән кирәкле документларның булуын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар.

Гамәлләр үтәүнең максималь срогы 15 минут.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече, КФҮ (КФҮ аша хезмәт күрсәтү шарты белән) мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.4. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

Гражданнарга консультация һәм мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыручы белгеч конфиденциаль мәгълүматны исәпкә алып уздырылган консультациянең тулылыгы, грамотлылыгы һәм аңлаешлылыгы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен читләштерү буенча алыш-биреш ясауга алдан рөхсәт бирү проектын әзерли һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә килештерү һәм раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча алыш-бирешләр ясауга алдан рөхсәт яки 3.7. пункт нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.4. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.7. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклау вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.7.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.7.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;
- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;
- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**
**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 985 номерлы карарына 15 кушымта

## 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан 4 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча гражданнарны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Гаилә кодексы (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 01.01.1996, № 1, 16 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31-нче номерлы 4179 ст.);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексы (алга таба - ТР ГК) (2009 елның 16 гыйнварындагы 8 номерлы Татарстан Республикасы);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 26.05.2004, № 21);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечи-тельлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы («Ватаным татарстан» 22.03.2008, № 54, Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008, Татарстан Дәүләт Советы ведомостьлары, № 3, март, 2008);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау

турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880-нче карары;

Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү | РФ Гаилә Кодексы 59 ст. ТР Гаилә Кодексы 50 ст. 8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | РФ Гаилә Кодексы 59 ст. ТР Гаилә Кодексы 50 ст. 8-ТРЗ номерлы ТР законы |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү боерык формасында яисә хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ Гаилә Кодексы 59 ст. ТР Гаилә Кодексы 50 ст. 8-ТРЗ номерлы ТР законы; |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Дәүләт хезмәте күрсәтүгә караган гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләрен карау теркәлгәннән соң 18 көн эчендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Балигъ булмаган затның фамилиясен (исемен) үзгәртү турында үтенеч белән бер ата-ананың гаризасы (1нче кушымта).<br>Балигъ булмаган затның фамилиясен (исемен) үзгәртү турында икенче ата-ананың гаризасы (ризалыгы) (2нче кушымта).<br>Ата-аналарның шәхесен раслаучы документлар (оригинал һәм күчермә).<br>10 яшькә җиткән балигъ булмаган баланың фамилиясен (исемен) үзгәртү турында ризалыгы. Гариза нигезендә ата-ананың берсеннән генә (икенчесе фикерен исәпкә алмыйча) рөхсәт алу өчен:<br>- башка ата-ананы эшкә сәләтсез дип тану турында суд карары күчермәсе;<br>-ата-ана хокукыннан мәхрүм итү турында суд карары күчермәсе;<br>- ата-ананың тәрбиядән һәм баланы социаль яклаудан баш тартуын раслаучы документлар;<br>Документлар бер нөсхәдә тапшырыла.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче опека органына шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Законда билгеләнгән тәртиптә расланган гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь йөртүчеләрдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла ала (җибәрелгән)<br>- шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат, ышанычнамә нигезендә);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар, шулай ук, мөрәҗәгать итүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша имзаланган электрон документ рәвешендә тапшырылырга мөмкин (җибәрелә). | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:<br>- Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булу-булмавын яки булмавын раслый торган белешмәләр һәм башка документлар рәвешләрен һәм Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактларының булу-булмавын раслаучы белешмә һәм башка документлар формаларын тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы приказы белән расланган 2 номерлы форма буенча туу турында белешмә (Граждан хәле актларын теркәү органнарында);<br>- Эчке эшләр органнарының эзләнә торган ата-ананың урнашу урыны билгеләнмәгәнлеге турындагы белешмәсе.<br>- Бала туу турында таныклык.<br>- ата-аналар баланың исемен һәм (яки) баланың фамилиясен үзгәртүне сорый торган документлар күчермәләре (аерылышу яки язылышу турында таныклык, ата-ананың фамилиясен үзгәртү турында таныклык яки аларның берсе һ.б.).<br>- ата булуын билгеләү турында таныклык (ата булуны билгеләү очрагында).<br>- бер эти-әнинең үлеме турында таныклык күчермәсе.<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән, шул исәптән мөмкинлекләре булган очракта да, үз эченә алган документларны тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуы өчен нигез булып тормый.<br>Мөрәҗәгать итүче әлеге регламентның 2.5 пункты белән мөрәҗәгать итә ала торган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе билгеләнгән. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүчедән таләп итү тыела:<br>-дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне башкару өчен документлар һәм мәгълүмат бирү;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләре күрсәткән өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат бирү, алар, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары карамагында тора;<br>-дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдә, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясы 1 өлеше 4 пунктында каралган очраклардан тыш, документларның булмавы һәм (яки) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат бирү | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, норматив хокукый актларда каралган очракларда алар белән килештерү таләп ителгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать фактик яшәү урыны буенча бирелмәгән | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Баш тарту өчен нигезләр:<br>- тапшырылган документларның әлеге административ регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>опекага алынган затның граждан һәм милек хокукларын кысу | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтүне сораганда һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта, чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соравын теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү тиешенчә җиһазландырылган биналарда гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда башкарыла.<br>1. Гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 423800, Яр Чаллы шәһәре, М. Җәлил урамы, 46 йорт, 310 кабинет, опека һәм попечительлек бүлеге.<br>2. Гариза бирүчеләрне кабул итү хезмәтләрне кулланучылар белән эшләү өчен җайлаштырылган бинада гамәлгә ашырыла.<br>3. Бүлек белгеченең эш урыны гариза бирүчеләрне кабул итү өчен электрон белешмә-хокукый системаларга керү мөмкинлеге булган шәхси компьютер һәм хезмәтне тулы күләмдә башкаруны оештырырга мөмкинлек бирүче оргтехника белән җиһазландырыла.<br>4. Документларны тутыру урыны урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырыла һәм документлар тутыру үрнәкләре, гариза бланклары һәм канцелярия кирәк-яраклары белән тәэмин ителә.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-чыгу һәм хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган урында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан документлар кабул иткәндә һәм тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтләрен электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет кабул итү бүлмәсе аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гариза һәм документларны кабул итү;

3) 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү бирүне әзерләү;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен бирү;

5) мөрәҗәгать итүчегә нигез булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы 4-нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Конс ультация бирү

Мәгълүмат бирү һәм консультация процедуралары кысаларында гражданнарга консультация бирү һәм мәгълүмат бирү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен җайга салучы норматив хокукый актлар турында мәгълүмат бирә;

- 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе белән мөрәҗәгать итүчене һәм аларның хокуклы вәкилен таныштыра;

- 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар исемлеген тәкъдим итә.

Консультация гариза бирүченең мөрәҗәгать итү көнендә телдән үткәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителгән документның составы, формасы һәм хезмәтләр күрсәтү алуның башка мәсьәләләре буенча консультация.

Консультация бирү һәм мәгълүмат бирү буенча административ процедураларның гомуми срогы - 15 минут.

3.3. Мөрәҗәгать итүче, 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, шәхсән гариза бирә.

Гариза һәм документларны кабул итү өчен җаваплы опека һәм попечительлек бүлеге белгече:

- гражданның шәхесен, балигъ булмаган затның яшәү урынын ачыклый;

- мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән кирәкле документларның булуын тикшерә. Кирәкле документлар булмаган очракта, документларны бирергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче документларын кабул итүне таләп итә икән, документлар кабул ителә;

- документлар пакетын формалаштыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән документлар

Гамәлләр үтәүнең максималь срогы 15 минут.

Әлеге Регламентның 2.8. пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булмаганда, опека һәм попечительлек бүлеге белгече, КФҮ (КФҮ аша хезмәт күрсәтү шарты белән) мөрәҗәгать итүчегә гариза һәм документларны кабул итү, керү номеры бирелү турында хәбәр итә, шуннан соң әлеге Регламентның 3.4. пунктчасында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә 15 минутта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарны кабул итү журналында теркәү язуы.

3.4. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүче биргән документларда булган мәгълүматларны тикшерә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм рөхсәт әзерләү яки баш тарту турында карар кабул итү.

3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече (мөрәҗәгать итүче белән алдан килештереп) электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша әлеге регламентның 2.6 пунктында каралган документлар бирү турында сорату җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар бирү турында сорату.

3.5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан опека һәм попечительлек бүлеге соравы буенча автоматлаштырылган режимда башкарыла:

- соратуны эшкәртү һәм соратылган мәгълүматларны эзләү;

- соратып алына торган мәгълүматларның ведомствоара электрон хезмәттәшлеге аша формалаштыру, яисә, соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта, соратып алына торган белешмәләр бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында хәбәр җибәрү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар опека һәм попечительлек органнары соратулары кергән вакыттан алып 5 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: соратуга җавап яки әлеге Регламентның 2.6. пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

### 3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.6.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече тапшырылган документлар нигезендә 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында боерык проекты әзерли Һәм аны опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә килештерүгә һәм раслауга җибәрә яки тиешле раслау белән баш тарту турында хат әзерли

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: 14 яше тулмаган баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү турында боерык, яисә 3.8. пункты нигезендә әзерләнгән хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат.

### 3.7. Гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирү.

3.7.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече, кул куелган боерыкны алгач, аны терки һәм мөрәҗәгать итүче кулына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.5.1. пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

### 3.8. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат бирү.

3.8.1. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече рөхсәт бирүдән бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проектын әзерли.

Баш тарту турында әзерләнгән хат проекты опека һәм попечительлек органы җитәкчесенә имзалауга җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар баш тарту өчен нигезләрне ачыклау вакытыннан алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында хат проектын имзалауга җибәрү.

3.8.2. Опека һәм попечительлек органы җитәкчесе баш тарту турында хатны имзалый һәм опека һәм попечительлек бүлеге белгеченә кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: баш тарту турында имзаланган хат.

3.8.3. Опека һәм попечительлек бүлеге белгече гариза бирүчегә кул куелган көннән алып бер эш көне эчендә баш тарту турында хатны җиткерә. Бер үк вакытта мөрәҗәгать итүчегә карарга шикаять бирү тәртибе аңлатыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар 3.7.2. пунктчасы белән каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хәбәр итү.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, жирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

- билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

- дәүләт хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен билгеләнгән тәртиптә тикшереп тору.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу ачыкланган очракта, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны тараткан очракта, мәгълүмат Башкарма комитет Җитәкчесенә гаепле затларны Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тарту өчен җибәрелә.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

Планлы тикшерүләр 3 елга 1 тапкыр үткәрелергә мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешен, белгечләр тарафыннан карарлар кабул итү, дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту, шулай ук конфиденциаль мәгълүматларны таратмауны агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләренең җаваплылыгы аларның вазыйфаи регламентларында закон таләпләре нигезендә беркетелә.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылыкка ия.

4.5. Хезмәт к үрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә эшчәнлекнең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

Мөрәҗәгать итүче шикаять белән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросны теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы норматив хокукый актлары белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Тукай муниципаль районының башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) мөрәҗәгать итүчедән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актларында каралмаган түләү алу;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктату нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса;

10) документларны кабул итүдән беренче баш тартканда юклыгы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү.

5.1. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләре югары органга бирелә яки ул булмаганда турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала.

5.2. Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (функцияләре) (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүче шәхси мөрәҗәгать иткән вакытта кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга шикаять бирү һәм карау үзенчәлекләре РФ субъектлары норматив хокукый актлары һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә мөрәҗәгать итүченең – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм җавап бирү өчен почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының карары һәм гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәгәнне раслаучы дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлык һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән каралмаган акчаларны кире кайтару һ.б. рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.6 Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5. 7. Шикаять тиешле дәрәҗәдә канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм алга таба гамәлләр турында (аларны мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатында кылырга кирәк) мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы билгеләре яки җинаять билгеләре ачыкланса, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Кушымта**
**(белешмә өчен)**

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затлар реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сектор мөдире | (8-8552)70-17-44 | Valentina.Dozorova@tatar.ru |
| Белгеч | (8-8552)70-17-44 | Opeka.tuk@mail.ru |

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | (8-8552)70-11-06 | Khabibullin.Ayrat@tatar.ru |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | (8-8552)70-09-66 | Ilfak.Bariev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31.03 мартындагы 85 номерлы карарына 16 кушымта

**Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче граждannar тарафыннан (түләүле һәм түләүсез шартларда) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге административ регламент (алга таба – регламент) муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче граждannar тарафыннан (түләүле һәм түләүсез шартларда) ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека (попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар: физик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: 423800, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт.

Опека һәм попечительлек органының кабул итү графигы: көн саен шимбә һәм якшәмбедән тыш;

дүшәмбе, чәршәмбе, җомга – документлар белән эшләү;

сишәмбе - пәнҗешәмбе 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр – шәхси сораулар буенча граждannarны кабул итү; төшке аш 12.00-13.00 сәг.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. Башкарма комитетның кабул итү бүлмәсе телефоны: 8(8552)70-00-76, опека һәм попечительлек секторының телефоны: 8(8552)70-17-44.

1.3.3. Рәсми сайт адресы: http://tukay.tatar.ru, электрон почта адресы: opeka.tuk@mail.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

опекун яки попечитель белән эшләү өчен биналарда урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

Мәгълүмат стендларында урнаштырылган мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 1.4, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны үз эченә ала.

Башкарма комитетта телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

«Интернет» челтәре аша:

районның рәсми сайты аша (http:// www. tukay.tatar.ru.);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi. tatar.ru/);

Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша (http:// www.gosuslugi.ru/).

1.4. Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

1995 елның 29 декабрендәге 223-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Гаилә кодексы (алга таба - РФ ГК) (РФ законнар җыелмасы, 01.01.1996, № 1, 16 ст.);

«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 48-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 28.04.2008, № 17, 1755 ст.);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31 номерлы 4179 ст.);

«Балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы РФ Хөкүмәте карары (алга таба - РФ Хөкүмәтенең 423 номерлы карары);

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә Кодексы (Татарстан Республикасы, 16.01.2009, № 8);

«Татарстан Республикасында опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2004 елның 27 февралендәге 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 8-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 26.05.2004, № 21);

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - 7-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 60-61, 25.03.2008, Татарстан Дәүләт Советы ведомостьлары, № 3, март, 2008, 212 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2008 ел, 1 декабрь, 843 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 843 номерлы карары);

Тукай муниципаль районы Советының 2012 елның 20 июнендәге 13/1 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы уставы (алга таба – устав);

Тукай муниципаль районы Советының 2005 елның 22 декабрендәге 4/14 санлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2019 елның 20 июлендәге 2505 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек секторы турында нигезләмә (алга таба – сектор турында нигезләмә);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 мартындагы 343 санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- опека – суд тарафыннан эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (опекуннар) опекуннарның законлы вәкилләре булып торалар һәм алар исеменнән һәм аларның мәнфәгатьләрендә юридик яктан әһәмиятле барлык гамәлләрне кылалар;

- попечительлек – суд тарафыннан эшкә сәләте чикләнгән гражданнарны урнаштыру формасы, аның нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан билгеләнгән гражданнар (попечительләр) балигъ булмаганнарга РФ ГК 30 маддәсе нигезендә гамәлләр кылырга ризалык бирергә тиеш;

- опекадагы зат – аңа карата опека яки попечительлек билгеләнгән граждан;

- эшкә сәләтсез граждан – РФ ГК 29 маддәсендә каралган нигезләр буенча суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган граждан;

- техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән, документларга кертелгән мәгълүматларның документлардагы мәгълүматларга туры килмәгән хата (ялгыш язу, грамматик яки арифметик хата);

- әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтүне сорау аңлашыла (210-ФЗ санлы Федераль законның 2 маддәсе 2 пункты, 27.07.2010 ел). Гариза Башкарма комитет карары белән расланган үрнәк яки стандарт бланкта ирекле формада тутырыла;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультация бирү.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Стандартка таләп исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү исеме | Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (түләүле һәм түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү | РФ ГК 31 ст.<br>РФ Гаилә кодексы 145 ст. 48-ФЗ номерлы Федераль закон 11 ст.<br>423 номерлы РФ Хөкүмәте карары<br>ТР Гаилә кодексы 133 ст. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Башкарма комитет | 48-ФЗ номерлы Федераль закон 843 номерлы ТР МК карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен | Опекун билгеләү турында карар (боерык); Гражданны опекун | РФ ГК |

| | | |
|---|---|---|
| тасвирлау | булырга теләк белдергән граждан буларак исәпкә кую өчен опекун булырга мөмкинлеге турында карар (бәяләмә);<br>Балигъ булмаган балага карата опека һәм попечительлекне түләүле шартларда булдыру турында шартнамә (опека (попечительлек) түләүле шартларда). | РФ Гаилә кодексы 48-ФЗ номерлы Федераль закон 423 номерлы РФ Хөкүмәте карары 1716 номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Опека (попечительлек) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү гаризаны теркәгән көннән соң 17 эш көнендә гамәлгә ашырыла. Опека (попечительлек) турында шартнамә төзү опека һәм попечительлек органы тарафыннан опека (попечительлек) билгеләү турында Карар (боерык) кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла. | 423 номерлы РФ Хөкүмәте карары 1716 номерлы РФ Хөкүмәте карары |
